

Саранск шәһәрендә урнашкан «Рухи-мәдәни үзәк» директоры урынбасары, Мордовия татар хатын-кызларынын «Чулпан» ижтимагый оешмасы рәисе Надия Низаметдин кызы Азисова Мордовия Республикасы Конституциясенен 30 еллыгы алдыннан регионыбыз топ законы турында фикере белән уртаклашты. Ул:

- 1995 елнын 21 сентябрендә Мордовия җомһүрияте конституциясе кабул ителә. Мордовия Конституциясе барлыкка килгәннән сон жәмгыятьтә чын патриотизм хисе генә түгел, ә үз гражданлык жаваплылыгын анлау да остенлек алган. Конституция республикадагы сәяси вәзгыятьне тотрыкландыруга зур олеш кертте, Мордовиянен Россиянен бердәм хокукый кырына керү курсын ныгытты, тобәкнен социаль-икътисадый системасын алга таба үстерүне тәэмин итте. Конституция Мордовия Республикасы законнары һәм башка норматив актлары тозелә торган хокукый системанын нигезе булып тора. Шул ук вакытта ул Мордовиянен Россия Федерациясенен тигез хокуклы субъекты булуын ныгыта.

Конституция - Мордовия халкынын барлык мәнфәгатьләрен үз эченә туплап, омет-хыялларын чагылдыра, киләчәккә ышанычын беркетә. Торле милләт һәм дин вәкилләре арасында үзара анлашу хакимлек иткән тобәк буларак, Мордовия коннән-кон кинрәк таныла бара, даны еракларга тарала. Конституцияле халык – дәүләтле халык ул. Безнен ботен нәрсәгә дә хокукларыбыз бар. Без Россия Конституциясе белән берлектә, анын нигезендә яшибез. Конституцияне белергә, ойрәнергә кирәк.